ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
IV чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИ-
ПАЛЬНОГО РАЙОНА
IV созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**15 нче ноябрь, 2024 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№38-06**

**«Актаныш муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны билгеләү нормативлары турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2023 елның 10 февралендәге 27-03 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны билгеләү нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге № 829 номерлы карары, (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары 24.04.2018 № 281, 14.06.2018 № 481, 17.10.2018 № 940, 29.12.2018 № 1320, 17.11.2021 № 1087, 13.12.2021 № 1222, 17.09.2022 № 1015, 30.04.2024 № 290, 24.06.2024 № 451 кертелгән үзгәрешләр белән), Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Актаныш муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны билгеләү нормативлары турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2023 елның 10 февралендәге 27-03 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «13323» саннарын «13990» саннарына алмаштырырга,

күрсәтелгән карарга 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Советы Рәисе

Л.Р.Зарипов

1 нче кушымта
Актаныш муниципаль районы
Советы карарына
15.11.2024 ел, №38-06

3 нче кушымта
Актаныш муниципаль районы
Советы карарына
10.02.2023ел, № 27-03

**Актаныш муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгының, депутатларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, контроль-хисап органы аудиторы рәисе, рәис урынбасарының айлык акчалата бүләкләү күләме**

| Вазыйфа атамасы | Айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда)<br>8 төркем |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | |
| Депутатлар | |
| Җирле үзидарәнең сайланган органнары әгъзалары | |
| Контроль-хисап органы рәисе | |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | |
| Контроль-хисап органы аудиторы | |